СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.10.2022 с. Сарманово № 104

**03.10.2022 г. № 104**

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2011 елның 21 сентябрендәге 41 номерлы карарына үзгәреш кертү турында**

Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын булдыру һәм куллану тәртибен билгеләү, алардан файдалану турында хисап бирү максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясына, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2011 елның 21 сентябрендәге 41 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктын «гуманитар ярдәм күрсәтү» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Донецк Халык республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу өчен мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаиләләре әгъзаларына көтелмәгән чыгымнарны тәэмин итүгә, шул исәптән:

- мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына матди, бер үк вакытта финанс һәм башка ярдәм күрсәтү;

- Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариаты тарафыннан бирелгән исемлекләргә ярашлы махсус хәрби операциядә катнашу өчен әзерлек чаралары вакытында затларга медицина тикшерүе, теш протезы, әйберләр белән тәэмин итү, туклану һәм йөрү өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү.

2. «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль

районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының финанс-бюджет мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы

Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин